МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2024 Казан ш № под-619/24

Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 декабрендәге под-1704/21 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының балаларга мәктәпкәчә белем бирү бүлегенә (Й.Ш.Хисамиева) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары М.З.Закировка йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм
фән министрлыгының 21.03.2024
№под-619/24 боерыгы белән расланды

Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент) балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм юллау буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

балигъ булмаган баланың законлы вәкиле (ата-аналарның берсе, опекуннарның берсе) (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затлар яклый ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә исәпкә кую һәм җибәрү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) карамагындагы мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында Оешма Министрлык белән хезмәттәшлек итә.

2.2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр катнашмый.

2.2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Оешмага мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына һәм оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле, дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм

мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәт күрсәтүләрдән тыш, гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны таләп итү тыела.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып дәүләт мәгариф оешмасында урын бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую һәм дәүләт мәгариф оешмасына җибәрү тора.

2.3.2. Әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча дәүләт мәгариф оешмасында урын бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар.

2.3.3. Әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасы һәм 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча дәүләт мәгариф оешмасына җибәрү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар.

2.3.4. Әлеге Административ регламентның 5 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

1) Оешмага шәхсән барган очракта – кәгазь чыганакларда;
2) почта аша җибәрү юлы белән;
3) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) ярашлы рәвештә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (https://www.gosuslugi.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) төбәк порталы (алга таба – Төбәк порталы) (www.uslugi.tatar.ru) имзаланган (расланган) электрон формада.

2.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу факты «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба – «ЭББ» АМС) теркәлә.

2.3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең телефоны һәм электрон почтасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар датасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар номеры;

гариза бирелгән көн;

гариза номеры;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итүгә вәкаләтле хезмәткәр вазыйфасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итүгә вәкаләтле хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең телефоны һәм электрон почтасы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар датасы:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар номеры:

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктына ярашлы рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе;

гариза бирелгән көн;

гариза номеры;

карар кабул итүгә вәкаләтле хезмәткәрнең вазыйфасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көнлек чорда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда яки Төбәк порталындагы шәхси кабинеты аша бирелгән очракта, исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Бердәм порталда яки Төбәк порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында күренә торган номер һәм «Мөрәҗәгать итүче белешмәләре расланганны таләп итә» статусы бирелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көнлек срокта күрсәтелә.

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша, шәхсән, мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда яки Төбәк порталындагы шәхси кабинеты аша бирелгән икән, Оешмага җибәрү өлешендә дәүләт хезмәте урын бирү турында документ расланган көннән алып бер көн эчендә күрсәтелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Бердәм порталда, Төбәк порталында, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт мәгариф оешмасында урын бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую һәм дәүләт мәгариф оешмасына юллау буенча дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) Гариза:

кәгазь документ формасында (әлеге Регламентка 7 нче кушымта нигезендә);

электрон формада (интерактив формага тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла), 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә ярашлы рәвештә имзаланып, Бердәм портал яки Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә (6 нчы кушымта).

2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта тапшырыла). Бердәм портал яки Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – Бердәм система)» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган зат булган мөрәҗәгать итүче «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясына ярашлы рәвештә чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документны тапшыра.

3) баланың кайда булуы, кайда яшәве турында мәгълүматлар булган документ (баланың яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә булган урыны буенча теркәлү турында таныклык булмаганда).

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең мәнфәгатьләрен таныклый торган документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш).

Мәктәпкәчә белем бирүнең адаптацияләнгән гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Оешмаларда дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

җайлаштырылган белем бирү программасы буенча (мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен) белем алуга психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе яисә сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә укытуга ихтыяҗны раслый торган документ.

Чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар булган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә баланың шәхесен раслаучы һәм бала хокукларында эш итүнең законлылыгын раслаучы документларны, шулай ук мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документны күрсәтәләр. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә рес теленә тәрҗемәсен таныклап тапшыралар.

Әгәр мөрәҗәгать итүче Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта юллауга хокуклы булса, ул үзендә күрсәтелгән хокукның булуын раслый торган документларны мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче кирәкле документларны тапшырмаган очракта, Оешма хезмәткәре аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә соратып ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен башка документлар бирүне таләп итү рөхсәт ителми.

Мөрәҗәгать итүче үзе теләгәнчә башка документлар тапшыра ала.

Гаризаның кәгазь формасы мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры Оешмада алынырга мөмкин.

Электрон формада гариза бланкы Оешманың рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Оешмага шәхсән барган очракта – кәгазь чыганакларда;
2) почта аша җибәрү юлы белән;
3) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (танылканган) электрон формада Бердәм портал яки Төбәк порталы аша.

Гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә, документлар законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланырга тиеш.

2.6.3. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал яки Төбәк порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән таныклана.

Имза төренә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителгән электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

Гаризаны Бердәм портал яки Төбәк порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы яки Төбәк порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны Бердәм портал яки Төбәк порталы аша тапшырганда, мөрәҗәгать итүче документларның 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон рәвешләрен яки документларны электрон формада тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш) Бердәм портал яки Төбәк порталы ярдәмендә

җибәрелгәндә, мөрәҗәгать итүче электрон документларның үрнәкләрен мондый документларны электрон рәвештә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап, шул исәптән мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, нотариуслар тарафыннан имзалатып тапшыра.

2.6.4. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелергә тиешле документлар, белешмәләр:

бала туу турында белешмәләр – Федераль салым хезмәте (алга таба – Федераль салым хезмәте), «Гражданлык хәле актларын теркәү буенча бердәм дәүләт реестры» (алга таба – ГХАТ БДР);

опека билгеләнүенраслый торган документ – опека һәм попечительлек органнары;

баланы Оешмага кабул итү өчен билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе – территориаль сәламәтлек саклау органнары;

баланы яшәү урыны яисә беркетелгән территориядә булу урыны буенча теркәү турында таныклык яисә баланың булу урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләр булган документлар – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары;

мөрәҗәгать итүченең Оешмага беренче чиратта, чираттан тыш юнәлешкә хокукы булуын раслый торган документлар (белешмәләр) (әлеге документлар тиешле органнарга мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта) – тиешле органнарга;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслаучы белешмәләр – Федераль нотариаль палата, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документларны, белешмәләрне тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә (гаризаны кәгазь рәвештә биргәндә) тулы булмаган мәгълүмат (мөрәҗәгать итүчедән тулы булмаган документлар комплектын) бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына бирелеп, хезмәт күрсәтү алар вәкаләтләренә кермәсә (гаризаны кәгазь чыганакта биргәндә);

бирелгән документларда Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә (кәгазь чыганакта гариза биргәндә) расланмаган текстны бозу, чистарту, төзәтү урыннары булганда.

Бердәм порталда яки Төбәк порталында баланың гаризада күрсәтелгән бертөрле мәгълүматларын үз эченә алган гариза булуы (гаризаны кәгазь чыганакта биргәндә).

2.7.2. Дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш

тарту турында карарны, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты имзалый һәм мөрәҗәгать итүчегә ул сайлаган ысул белән җибәрә:

1) Оешмага шәхсән барган очракта, – кәгазь чыганакларда;

2) почта аша җибәрү юлы белән;

3) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон формада Бердәм портал яки Төбәк порталы аша.

2.7.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яки Төбәк порталында, Оешманың рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела

2.8.Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтү хокукына ия булган затлар категориясенә туры килмәве;

әлеге Административ регламентның 2.6.1, 2.6.4 пунктлары нигезендә төгәл булмаган мәгълүмат бирү;

- бирелгән документларның яки белешмәләрнең хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

- гариза формасында мәҗбүри кырларны, шул исәптән Бердәм порталда яки Төбәк порталында гаризаның интерактив формасында мәҗбүри кырларны корректлы тутырмау (төгәл булмаган, тулы булмаган яки дөрес булмаган итеп тутыру) (гаризаны электрон рәвештә биргәндә);

- тулы булмаган мәгълүмат бирү, шул исәптән тулы булмаган документлар комплекты тапшыру (гаризаны электрон рәвештә биргәндә);

Юллама бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә ул сайлаган ысул белән җибәрелә:

1) Оешмага шәхсән барган очракта, – кәгазь чыганакларда;

2) почта аша җибәрү юлы белән;

3) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон формада Бердәм портал яки Төбәк порталы аша.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яки Төбәк порталында, Оешманың рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела

2.8.5. Оешмада урыннар булмаган очракта, баланың әти-әнисе (законлы вәкилләре) аны башка Оешмага урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.8.6. Мөрәҗәгать итүче шәхси язма гаризасы нигезендә хезмәт күрсәтүдән баш тартырга хокуклы.

Язмача баш тарту хезмәт күрсәтү өчен кабат мөрәҗәгать итүгә комачауламый.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Оешмада алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша җибәргәндә, аны теркәү гариза килгән көнне башкарыла.

Гаризаны Бердәм портал яки Төбәк порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Бердәм порталдагы яки Төбәк порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

Гаризаны теркәү дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында башкарыла, гариза биргәндә (тулысынча автоматлаштырылган хезмәтләр өчен).

2.11.1. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында законнар нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү

мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска ярдәмендә дә;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу үзлеге бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

9) дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, Оешманың рәсми сайтында, Бердәм порталда яки Төбәк порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында, шул исәптән Бердәм порталны яки Төбәк порталын кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге.

мөрәҗәгать итүче тарафыннан, шул исәптән Бердәм портал яки Төбәк порталы аша, дәүләт мәгариф оешмасында урын урын бирү эзлеклелеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

3) Оешма һәм Министрлык хезмәткәрләренең Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле барлык документлар белән гариза биргән вакытта мөрәҗәгать итүче бер тапкыр Оешма хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итә;

Оешмада дәүләт хезмәте күрсәтүнең электрон документ формасындагы нәтиҗәсен кәгазьдә алу зарурлыгы булган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы унбиш минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталыннан яки Төбәк порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яки Төбәк порталында «Шәхси кабинет» аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге, алдан авторизация узмыйча гына, Бердәм порталда яки Төбәк порталында «Шәхси кабинет» аша гамәлгә ашырыла.

«Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң, мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яки Төбәк порталында түбәндәге мөмкинлекләрне ала:

Бердәм портал яки Төбәк порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирү;

кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү процедурасын узарга кирәк. Бердәм системада алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

Бердәм системада (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүче – физик зат гади электрон имзаны кулланып Бердәм порталда яки Төбәк порталында авторизация узарга тиеш. Бердәм порталда яки Төбәк порталында «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән

гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

Экстерриториаль тәртип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль тәртиптә күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы

2.14.3. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре.

2.14.3.1. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда яки Төбәк порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Төбәк порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Оешма, Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда яки Төбәк порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.3.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) Бердәм системада булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда яки Төбәк порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон форма кырларын тутыру;

5) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

6) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;

2) гариза бирүче тәкъдим иткән гаризаны һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау, гаризаны «ЭББ» АМС системасында теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) җибәрелгән хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә (алга таба – мөрәҗәгать итүчене консультацияләү).

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе консультацияне башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче Оешмага мөрәҗәгать иткән очракта – Оешма хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәре.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче Оешмага шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Төбәк порталыннан, Оешма сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны Оешма сайтыннан, Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Оешма хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Әлеге пунктта каралган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан, Министрлык сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта каралган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаны һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны почта аша, Оешмага шәхсән, Бердәм портал яки Төбәк портал аша бирә ала.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Оешма аша кабул итү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән Оешмага мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Төбәк порталы аша электрон формада кабул итү.

Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү белешмәсен раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга билгели);

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Оешмага җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Оешма тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның Оешма тарафыннан алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

3.3.3.2. Оешманың документларны кабул итү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә, тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.7.1. пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга белдерелә торган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәнең) атамасы турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш), килештерү өчен электрон документ әйләнеше ярдәмендә җибәрелә.

Әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки сканер аша уздырылган документларның электрон рәвешләрен кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара.

гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында белдерү җибәрә, анда гаризаның кергәндә теркәлгән номеры, гаризаны алу датасы, аңа теркәлгән файлларның, документларның исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) Бердәм системада булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, Бердәм системада урнаштырылган һәм Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон форма кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) Бердәм порталда кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: документлар комплекты белән теркәлгән гариза, Министрлыкка җибәрелгән электрон эш яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.3.3.3. Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал яки Төбәк порталы аша электрон формада мөрәҗәгать иткән очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

килгән электрон эшләрне өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә.

гаризаны эшкә кабул итүне тәэмин итә. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал һәм/яки Төбәк порталы аша «Гариза карала башлады» дигән хәбәр җибәрелә;

документларны дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына йөкли.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның тулы комплекты тапшырылмаган очракта һәм гариза белешмәләрен раслау таләп ителгәндә, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта Бердәм порталда яки Төбәк порталында хәбәр итү формасы буенча хәбәр ителә «Гариза белешмәләрен раслау өчен Сезгә түбәндәге оешмага ________________ (документларны тапшыру урыны күрсәтелә) ________________ срокта (документларны тапшыру срогы күрсәтелә) әлеге документларны тапшырырга кирәк: ________________ (мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле, раслау документларның исемлеге күрсәтелә).» Әлеге кимчелекләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән көннән алып бер эш көне эчендә төзәтелергә мөмкин, шул исәптән, әлеге Административ регламентның 2.8.2 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту каралган тиешле хәбәр кергәндә дә. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал яки Төбәк порталы аша хәбәр җибәрелә «Сезгә агымдагы гариза буенча хезмәт күрсәтүдән баш тартылды ________________ (гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбе күрсәтелә). Сезгә эшләргә кирәк________________ (гариза буенча мөрәҗәгать итүчегә уңай нәтиҗә алу өчен башкарылырга тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә).».

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: документлар комплекты белән теркәлгән гариза, Министрлыкка җибәрелгән электрон эш яки мәгълүматны раслау кирәклеге турында хәбәр.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.4.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

бала туу турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать ФСХ, ГХАТ БДР җибәрелә;

опека билгеләүне раслый торган документ. Рәсми мөрәҗәгать опека һәм попечительлек органнарына җибәрелә;

баланы Оешмага кабул итү өчен билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе. Рәсми мөрәҗәгать сәламәтлек саклау буенча территориаль органнарга җибәрелә;

баланы яшәү урыны яисә беркетелгән территориядә булу урыны буенча теркәү турында таныклык яисә баланың булу урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләр булган документлар – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары;

мөрәҗәгать итүченең Оешмага беренче чиратта, чираттан тыш юнәлешкә хокукы булуын раслый торган документлар (белешмәләр) (әлеге документлар тиешле органнарга мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта).

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслаучы белешмәләр – Федераль нотариаль палата, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.4.2.2. Әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш итеә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.2.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.4.3. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр алынган көнне үтәлә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.4. Әлеге Регламентның 3.4.2.1. пунктчасында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны теркәгән вакыттан башлап, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Исәпкә кую.

Процедураны башкару өчен җаваплы булган вазыйфаи зат килгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат нигезендә:

тапшырылган документларны тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булуын (булмавын) билгели;

исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар проектын әзерли (әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта) яисә исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли (әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта);

карар проектын Оешманың вәкаләтле затына имзалау өчен җибәрә.

Бердәм портал яки Төбәк порталы аша алынган очракта, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталда яки Төбәк порталында хәбәр итү формасы аша хәбәр ителә: «Сезнең гаризагыз каралды. Гаризаның индивидуаль номеры _______________. Сайланган мәгариф оешмасына юллауны көтегез _______________ соң (гаризада күрсәтелгән, теләнгән кабул итү датасы күрсәтелә).» (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта) яисә «Агымдагы гариза буенча сезгә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылды, сәбәбе: _______________ (гариза буенча тискәре карар кабул ителгән сәбәп күрсәтелә). Сезгә эшләргә кирәк _______________ (гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә). (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта).

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша белешмәләр килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яисә исәпкә кую өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.5.2. Оешмага юллау.

3.5.2.1. Административ процедураны үти башлау өчен ЭББ АМС системасында гаризаның «Теркәлде» статусының булуы, баланы исәпкә кую, баланы теркәлгән

чират нигезендә баланы юллау өчен Оешмада буш урыннарның җитәрлек санда булуы нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүченең чираты килеп җиткәндә һәм теләнгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булганда, вәкаләтле хезмәткәрләр ЭББ АМС аша баланы Оешмага юллыйлар. Гаризага «Мәктәпкәчә белем оешмасына юлланды» статусы бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Оешмага урын бирү турындагы документ расланган көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Системада гаризага «Мәктәпкәчә белем оешмасына юлланды» статусын бирү.

3.5.2.2. Гариза бирүче «Мәктәпкәчә белем оешмасына юлланды» статусы бирелгәннән соң 30 календарь көнгә кадәр баланы кабул итүне раслау өчен Оешмага мөрәҗәгать итә.

Оешма җитәкчесе бала кабул итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәннән соң биш эш көне эчендә ЭББ АМС системасында гаризага «Килешү төзү» статусын бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәннән соң биш эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Килешү төзү» статусын бирү.

3.5.2.3. Әгәр дә бала җибәрелгән Оешма мөрәҗәгать итүчене канәгатьләндерми икән, мөрәҗәгать итүче әлеге Оешмага җибәрүдән баш тартуны рәсмиләштерә.

Тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту Министрлык билгеләгән форма буенча шәхси мөрәҗәгать иткәндә язма рәвештә рәсмиләштерелә.

ЭББ АМС системасында гаризага «Теркәлде» статусы бирелә. Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәрми. Теләнгән кабул итү датасы мөрәҗәгать итүченең юлламадан баш тарту турындагы мөрәҗәгате көненнән дә иртәрәк булмаган датага үзгәртелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Теркәлде» статусы бирү, тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту.

3.5.2.4. Мөрәҗәгать итүче Оешмага гаризага «Мәктәпкәчә белем оешмасына юлланды» статусы бирелгәннән соң Регламентның 3.5.2.2 пунктында күрсәтелгән срокта килмәсә, ЭББ АМС системасында гаризага «Килмәде» дигән статус автомат рәвештә бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.2.2 пунктында билгеләнгән срок беткән мизгелдән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Килмәде» статусын бирү.

3.5.2.5. Әгәр дә мөрәҗәгать итүче хезмәттән файдалану теләгeн раслый икән, гаризага «Теркәлде» статусы бирелә. Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәрми. Әгәр дә мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусы бирелә. Хезмәт алуны яки аннан баш тартуны раслау яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе органнарына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә

Министрлык билгеләгән форма буенча язмача рәвештә рәсмиләштерелә, Оешмага кабул итү датасын мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итү көненнән иртәрәк булмаган датага алмаштыру, дәүләт хезмәтен алу ихтыяҗын раслап.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Теркәлде» яки «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусын бирү.

3.5.3 Оешмага кабул итү.

3.5.3.1. «Килешү төзү» статусы бирелгәннән соң бер ай эчендә мөрәҗәгать итүче килешү төзү өчен Оешмага мөрәҗәгать итә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгәннән соң Оешма җитәкчесе ЭББ АМС системасында гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде» статусын бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде» статусын бирү.

3.5.4. Баланы билгеле бер вакытка компенсацияләү яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәргән очракта (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә), Оешманың вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан ЭББ АМС системасында юлламада «Вакытлыча кабул итү» билгесе куела.

Баланың гаризасы беренчел исәпкә кую датасы белән куелган чиратлылыкта саклана.

Әгәр бала компенсацияләү яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәрелгән вакытта башка Оешмага йөргән булса, Оешма җитәкчесе махсус төркемдә булу вакыты тәмамлану датасын күрсәтеп, баланы вакытлыча чыгарып тора.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризага «Вакытлыча кабул итү» статусын бирү.

3.5.5. Гаризага индивидуаль тәңгәллек номеры бирелгәннән соң теләнгән Оешманы мөрәҗәгать итүченең гаризасы буенча заявкада үзгәртергә рөхсәт ителә. Мөрәҗәгать итүче теләнгән Оешманы алмаштыру турында гаризаны Министрлыкка бирә.

Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәртелми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура теләнгән Оешманы алмаштыруга гариза алынганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче теләнгән Оешманы гаризада Бердәм порталда яки Төбәк порталында шәхси кабинетта үзгәртә ала.

Процедураның нәтиҗәсе: ЭББ АМС системасында гаризада теләнгән Оешманы үзгәртү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.6.1. Теркәлгән гаризага индивидуаль тәңгәллек номеры бирелә. Гаризаның статусын һәм Оешмага урнашу буенча чират торышын мөрәҗәгать итүче Бердәм

порталда яки Төбәк порталында шәхси кабинетта баланың туу турындагы таныклыгы белешмәләре (сериясе һәм номеры) яки гаризаның индивидуаль тәңгәллек номеры буенча, шулай ук Министрлыкка кабул итү сәгатьләрендә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итеп тикшереп карый ала.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы һәм нәтиҗәсе турында мәгълүмат Бердәм порталда яки Төбәк порталында шәхси кабинетта гаризаның статусы («Теркәлде», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде», «Килешү төзү», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде», «Килмәде», «Вакытлыча кабул итү») үзгәрү турында хәбәрләр рәвешендә чагылдырыла.

Процедураны үтәү автомат режимда ЭББ АМС системасы ярдәмендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү барышы һәм нәтиҗәсе турында мәгълүмат бирү.

3.6.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Оешмага мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы хезмәткәр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирә (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә ул килгән көнне тапшырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе имзаланган көнне җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе булып бирелгән (җибәрелгән) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тора.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Оешмага түбәндәгеләрне җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә), Бердәм портал яисә Төбәк порталы аша җибәрелә.

Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм документларны теркәү датасыннан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатларында, документларны әзерләү процедурасын башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, опека һәм попечительлек

органына техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге процедуралар техник хата ачыкланган яки җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

**4. Административ регламент үтәлешен тикшереп тору формалары.**

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларны саклавын һәм үтәвен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүен агымдагы тикшереп тору Оешма җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.6. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Оешма эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне һәм

шикаятьләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Оешманың, Оешма хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә, гамәл кылмавына карата – Оешма җитәкчесенә, Оешма җитәкчесе, Министрлык хезмәткәрләре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына (алга таба – Министр), Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына судка кадәрге тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы, дәүләт хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләрне башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы караламган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Оешманың, Оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтын, Бердәм порталны, Төбәк порталын, судка кадәр шикаять итүнең мәгълүмат системасын кулланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Алынган шикаять кергән көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5. Шикаять аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта яки Оешмада гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентка № 1 кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү (исәпкә кую) турында
электрон рәвештә хәбәр итү формасы

Мәгълүмат бирү статусы: *Гариза каралды*

Мәгълүмат бирү статусына карата аңлатма.

«*Сезнең гариза каралды. Гаризаның индивидуаль номеры ________________. Сайланган мәгариф оешмасына (гаризада күрсәтелгән, теләнгән кабул итү датасы күрсәтелә) соң юллама булуын көтегез.*»

Дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентка № 2 кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар формасы (кәгазьдә)

________________________________________________________

*Оешманың атамасы*

Кемгә:

Исәпкә кую өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү йортына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтү турында

КАРАР

__________ №

Сезнең гаризагызны № һәм аңа теркәлә торган документларны карап

______________________________________________________________________

*Оешманың атамасы*

карар кабул ителде: *(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (атасының исеме – булган очракта)* дәүләт мәгариф оешмасында урын бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә куярга/ *(гаризада күрсәтелгән параметрларны санап чыгарга)*

____________________________________

*Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм ФИА* (ата исеме – булган очракта)

Дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентка № 3 кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт мәгариф оешмасына юллау)
турында электрон рәвештә хәбәр итү формасы

Мәгълүмат җиткерү статусы: *Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде*

Мәгълүмат бирү статусына карата аңлатма.

*«Сезгә урын бирелде (мәктәпкәчә белем бирү оешмасының исеме күрсәтелә, төркем турында белешмәләр), түбәндәгеләр нигезендә (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына юллау турында документ реквизитлары күрсәтелә).*
*Сезгә кирәкле нәрсәләр (статус күрсәтелгәннән соң гамәл кылу тәртибе күрсәтелә,*
*гамәлләрне башкару срогы күрсәтелә).»*

Дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентка № 4 кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар формасы
(кәгазьдә)

______________________________________________
*Оешманың атамасы*

Кемгә:

Дәүләт мәгариф оешмасына юллау өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү йортына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтү турында КАРАР

(кәгазьдә)

__________ №

Сезгә урын бирелде _________ (*мәктәпкәчә белем бирү оешмасының атамасы күрсәтелә,* төркемдә *(юнәлеше, коменсацияле һәм катнаш юнәлешләрдәше төркемнәр өчен төрен һәм савыктыру төркемнәре өчен төркем профилен күрсәтеп, төркемнең яшь күрсәткече),* тору режимы *(баланың төркемдә булу режимы күрсәтелә)* мәгариф программасы буенча укыту өчен *(мәгариф программасының атамасы һәм юнәлеше күрсәтелә (булган очракта))* телдә *(белем бирүнең тиешле теле күрсәтелә)*/түбәндәгеләр нигезендә караштырып тору һәм карау өчен *(баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына юллау турында документ реквизитлары күрсәтелә).*

Сезгә кирәкле нәрсәләр *(гамәлләрне башкару срогы белән, мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр тәртибе тасвирлана).*

______________________________________
*Фазыйфа һәм ФИА (ата исеме – булган очракта)*

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
административ регламентка № 5 кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар формасы

____________________________________________________________

*Оешманың атамасы*

Кемгә:

Исәпкә кую өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү йортына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында

КАРАР

___________ №

Агымдагы гариза буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында баш тартылды, чөнки *(гариза буенча тискәре карар кабул ителгән сәбәп күрсәтелә)*.

Сезгә кирәкле нәрсәләр *(гариза буенча мөрәҗәгать итүчегә уңай нәтиҗә алу өчен башкарылырга тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә)*.

____________________________________

*Карар кабул иткән хезмәткәрнең вазыйфасы һәм ФИА (ата исеме – булган очракта)*

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
административ регламентка № 6 кушымта

## Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә гариза формасы

____________________________________________
____________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), шәхесне раслый торган документ белешмәләре, элемтәгә керү өчен телефон, почта адресы, электрон почта адресы)*

Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

<table>
<tr><td>Т/с</td><td>Сораулар исемлеге</td><td colspan="2">Җаваплар</td></tr>
<tr><td>1.</td><td>Сез баланың ата-анасы яки законлы вәкиле булып торасыз</td><td>Ата-анасы</td><td>Законлы вәкиле</td></tr>
<tr><td colspan="4">Бердәм порталда мөрәҗәгать итүче профиленә караган белешмәләр автомат рәвештә тутырыла: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);<br>паспорт белешмәләре ( сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)<br>Әгәр ЗАКОНЛЫ ВӘКИЛ икән, ул вакытта өстәмә рәвештә электрон рәвештә бала хокукларында эш итүне раслый торган документ(лар) тапшырыла ала.<br>Өстәмә рәвештә ата-ананың (законлы вәкилләрнең) элемтә өчен белешмәләре (телефоны, электрон почта адресы (булган очракта)) күрсәтелә.</td></tr>
<tr><td>2.</td><td colspan="3">Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирелә торган баланың персональ белешмәләре:<br>(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта); туган көне, ае, елы;<br>баланың туу турындагы таныклыгының яки баланың шәхесен раслый торган башка документның реквизитлары[6];<br>яшәү урыны адресы.</td></tr>
</table>

____________________

| | |
|---|---|
| | Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең профилендә бала турында белешмәләр булган очракта, алар автомат рәвештә тутырыла. |
| 3. | Кабул итүнең теләнгән параметрлары: Кабул итүнең теләнгән датасы;<br>белем бирү теле (исемлектән сайлау);<br>баланың төркемдә (исемлектән сайларга) булу режимы;<br>төркемнең юнәлеше (исемлектән сайларга);<br>*Компенсация төркеме төре (коменсация юнәлешендәге төркемнәрне сайлаганда исемлектән сайлау);*<br>*Адаптацияләнгән программа (булган очракта) буенча укытуга ихтыяҗ булуын раслый торган документ реквизитлары;*<br>*Савыктыру төркеме профиле (савыктыру юнәлешендәге төркемнәрне сайлаганда исемлектән сайларга)*<br>*Савыктыру төркеменә (булган очракта) ихтыяҗ булуын раслый торган документ реквизитлары.*<br>Савыктыру яисә компенсацияләү төркеме сайлап алынган очракта, өстәмә рәвештә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ электрон рәвештә бирелергә мөмкин;<br>психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең реквизитлары (кирәк булганда). Өстәмә рәвештә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ электрон рәвештә бирелергә мөмкин;<br>кабул итү өчен белем бирү оешмалары (территорияләрне билгеле бер белем бирү оешмаларына беркетү нигезендә әлеге Административ регламентка кушымта нигезендә сайлап бирелә) |

| | |
|---|---|
| *Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлеге* | *дәүләт, мәгариф муниципаль, шулай ук килешүләр кысаларында сайланган башка оешмалар исемлегеннән күпсанлы сайлау мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт-хосусый, муниципаль-хосусый партнерлыкта кабул итү өчен, муниципаль берәмлектә (исемлек региональ мәгълүмат системаларында төзелә) сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының өстенлекләре күрсәтелеп, баланың яшәү адресына кертелгән, муниципаль берәмлектә (региональ мәгълүмат системаларында төзелә) сайлау; сайлап алырга мөмкин булган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының максималь саны мәгариф өлкәсендә идарә органы тарафыннан билгеләнә.* |

| | |
|---|---|
| *Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар булмаса, кабул итү өчен сайлап алынган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлегеннән тыш, башка мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына юллама алу* | *бинар, «Әйе/Юк» тамгасы,*<br>*башкача – «Юк»* |

| | | |
|---|---|---|
| | *Гомумиүсеш төркемнә ризалык* | *«Әйе/Юк» бинар тамгасы гомумиүсеш булмаган төркемне сайлаганда куела ала, башкача – «Юк»* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *Караштырып тору һәм карау төркеменә ризалык* | *бинар тамгасы «Әйе/Юк», башкача – «Юк»* |
| | | *Кыска вакытка килеп тору режимына ризалык* | *бинар тамгасы «Әйе/Юк», башкача – «Юк», көненә 5 сәгатьтән артык режимнарын сайлаганда тутырыла ала* |
| | | *Тулы көн төркеменә ризалык* | *бинар тамгасы «Әйе/Юк», башкача – «Юк», тулы көннән аермалы буларак, режим буенча төркемне сайлаганда тутырыла* |
| 4. | Кабул итү өчен сайланган белем оешмаларында инде белем ала торган, урын таләп ителгән башка балаларыгыз яки баланың абый-апалары (энеләре-сеңелләре) бармы? | Әйе | Юк |
| ӘЙЕ булса, аларның ФИА күрсәтегез һәм ул бала укый торган оешманы атагыз. ЮК икән, №5 адымга күчегез | | | |
| 5. | Сезнең махсус ярдәм чараларына хокукыгыз (чираттан тыш яки беренче чиратта кабул ителү хокукы) бармы | Әйе | Юк |
| Өстәмә рәвештә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ электрон рәвештә бирелергә мөмкин. | | | |

Дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентка №7
кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә кәгазь чыганакта гариза

Мин, *(ата-ананың (законлы вәкилнең) (ФИА (ата исеме – булган очракта), паспорт белешмәләре (вәкиллекне раслый торган документ реквизитлары)*, *ата-ана (законлы вәкил) буларак,* дәүләт мәгариф оешмасында урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую, шулай ук *(укытуның теләнгән вакыты) башлап дәүләт мәгариф оешмасына (белем бирү оешмасының атамасы)* белем алу мөмкинлеген биреп юллау турында үтенәм *(белем бирү телен, баланың төркемдә булу режимын, төркем юнәлешен, (булган очракта) психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе реквизитларын күрсәтеп) (баланың ФИА (ата исеме – булган очракта), туу датасы, туу турында таныклык (шәхесне раслый торган документ) реквизитлары,* яши торган адресы *(яшәү урыны адресы)*.

Күрсәтелгән белем бирү оешмасында кабул итү урыны булмаганда, укырга исемлек буенча түбәндәге белем бирү оешмаларына җибәрүне сорыйм *(өстенлек тәртибендә күрсәтелә).*

Миңа тиешле махсус ярдәм чаралары (чираттан тыш яки беренче чиратта кабулл ителү хокукы) белән бәйле рәвештә әлеге хезмәтне *чираттан тыш (беренче чиратта)* тәртиптә күрсәтүегезне сорыйм. Хокукны раслый торган, тиешле документлар теркәлә.

Белем бирү оешмасында (*өстенлекле рәвештә күрсәтелгән белем бирү оешмасының атамасы)* баланың абыйсы (апасы) укый *(гариза бирелә торган баланың ФИА (ата исеме - булган очракта) – абыйсының (апасының) ФИА (ата исеме - булган очракта))*.

Элемтә өчен белешмәләр: *ата-ананың (законлы вәкилләрнең) телефон номеры, электрон почта адресы (булган очракта).*

Кушымта: .

*мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар*

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә миңа хәбәр итәргә:

телефон аша: ______________________

әлеге электрон почта адресы буенча: ________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен миңа түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

Оешмага шәхсән барган очракта кәгазь чыганакларда: ___________;

почта аша җибәрү юлы белән: ;

Бердәм портал яки Төбәк порталы аша электрон формада: .

___________________________ ___________________________________

*(мөрәҗәгать итүче)* *(Имза)*

Дата: “ ” 20_ ел.